Татарстан Республикасы  БалыкБистәсемуниципаль районы
ТүбәнТегермәнлекавылҗирлегесоставынакерүче
Түбән Тегермәнлек авылыторакпунктындаузган
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ  КАРАРЫ**

2019  елның30 октябрь № 2

“Россия Федерациясендәҗирлеүзидарәоештыруныңгомумипринципларытурында” Федеральзаконның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының ”Татарстан Республикасындаҗирлеүзидарәтурында” Законының 35 маддәсенигезендә Татарстан Республикасы  Балык Бистәсе муниципаль районы  Троицкий Урай авыл җирлеге составына керүче  Түбән Тегермәнлек авылы торак пунктында  узган гражданнарҗыены  **КАРАР БИРӘ**:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль  районы Түбән Тегермәнлек  авыл җирлеге составына керүче Югары Тегермәнлек, Түбән Тегермәнлек авыл торак пунктларында  тору урыны буенча  теркәлгән  балигъ булган  һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан һәм 80 яшьтән узган пенсионерлардан  гайре,барлык теркәлгән гражданнарнын 30 процентыннан артмаган)  400 сум күләмендә үзара салым  акчасы кертергә;

2. Тупланган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлтергә:

- щебенка сатып алу ,юллар ремонтлау өчен   Фрунзе,Титов,Совет урамнары Югары Тегермәнлек авылы ; Фрунзе,К.Маркс урамнары Түбән Тегермәнлек авылы өчен ;
-каты көнкүреш калдыклары өчен контейнерлар сатып алу һәм урнаштыру өчен 2 данә;.
-Түбән Тегермәнлек авылы су башнясының санитар зонасын тотып алу өчен;
-кышын авыл җирлеге торак пунктларында  урамнарның йөри торган өлешләрен карап торуга (кардан  арындыруга);
-Түбән Тегермәнлек авылы ял паркы өчен инвентарь сатып алу өчен;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат  стендларында: Татарстан Республикасы  Балык Бистәсе районы Югары Тегермәнлек авылыСовет урамы, 72А йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Карарны Татарстан Республикасыүзидарәлекхокукый норматив актларырегистрынакертүөченҗибәрергә.

Гражданнар  җыенында рәислек итүче
Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге  башлыгы                    А.Н.Дмитриев